ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАХМАЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.45Б
с. Шахмайкино,423183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 нче сентябрь 2025 ел № 12

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башкарма комитеты 25.04.2022 №8 “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ :

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Башкарма комитетының “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 25.04.2022 №8 карарына (Шахмай авыл җирлеге Башкарма комитетының 6.02.2023 № 3; 28.10.2024 №13 карарлары редакциясендә) (алга таба – Регламент) регламентның 2 бүлеге 2.5.1 пунктына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

дүртенче пунктчада “мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк” сүзләрен “мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк” сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.) пунктчасы өстәргә:

“4.1.) Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы”нда бастырып

чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

Н.М. Илалова